СОВЕТ КУЗЕМБЕТЬЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423710,Республика Татарстан,
Мензелинский район, с,Кузембетьево
ул.Мирная, 72

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ХУЖЭМЭТ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423710, Татарстан Республикасы,
Минзәлә районы, Хужэмэт авылы, Мирная ур.72

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ХУҖӘМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАРЫ

**16 август 2019 ел**

**№ 1**

**Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Хуҗәмәт авыл җирлеге Советының“Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы “Хуҗәмәт авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында”гы Карар проекты турында**

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы №131-ФЗ Федераль законының 44 маддәсен, Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы “Хуҗәмәт авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставын кулланып, Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районының :

Хуҗәмәт авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. “Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы “Хуҗәмәт авыл җирлеге”муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында”гы Карар проектын хупларга һәм ачык тыңлауларга чыгарырга (Кушымта №1).

Расларга:

-“Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы “Хуҗәмәт авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында”гы Карар проектын ачык тыңлауларда уздыру тәртибен (Кушымта №2).

2. Гамәлдәге карарны рәсми стендта һәм Интернет мәгълүмати-коммуникацияле челтәрдә ТР Минзәлә муниципаль районының http://menzelinsk.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

3. “Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы “Хуҗәмәт авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында”гы Карар проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм тикшерү буенча түбәндәге составта эшче төркем булдырырга:

Каримов Х.Х – эшче төркем әгъзасы

Талипова З.В - эшче төркем әгъзасы

Гараев К.Р.- эшче төркем әгъзасы

4. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

-“Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы “Хуҗәмәт авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында”гы Карар проекты буенча тәкъдимнәр ТР Минзәлә муниципаль районы Хуҗәмәт авыл җирлеге Советына түбәндәге адрес буенча: ТР, Минзәлә районы, Хуҗәмәт авылы , Тынычлык урамы, 72, рәсми төстә басылганнан соң 20 көн эчендә, эш көннәрендә 8.00 -17.00 сәгатьләрдә, язмача формада.

--“Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы “Хуҗәмәт авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында”гы Карар проекты буенча ачык тыңлауларда чыгыш ясау хокукы белән катнашуга гарызнамәләр түбәндәге адрес буенча: ТР, Минзәлә муниципаль районы, , Хуҗәмәт авылы , Тынычлык урамы, 72 , эш көннәрендә 8.00 – 17.00 сәгатьләрдә яисә шәхсән, яисә почта аша (Конвертта “Уставны тикшерү” билгесе белән) бирелә.

5. Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы “Хуҗәмәт авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында”гы Карар проекты буенча ачык тыңлауларны 2019 елның 12 сентябрендә, 14.00 сәгатьтә, ТР Минзәлә муниципаль районы Хуҗәмәт авылы Мәдәният йорты : ТР, Минзәлә районы, Хуҗәмәт авылы, Совет ур., 33А йорт адресы буенча уздырырга.

6. Эшче төркемгә Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы “Хуҗәмәт авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында”гы Карар проектына тәкъдимнәрне өйрәнергә һәм гомумиләштерергә.

7. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет рәисе Г.Г.Вильданова

**ПРОЕКТ**

ТР Минзәлә муниципаль районының
Хуҗәмәт авыл жирлеге Советы карарына
Кушымта №1
16.08.2019 № 1

Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль районының Хуҗәмәт авыл җирлеге
Советы
КАРАРЫ

№ ________ ___________________

**Татарстан Республикасы**
**Минзәлә муниципаль районы** Хуҗәмәт авыл җирлеге **Советының**
**"Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы "Хуҗәмәт авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында"гы Карар проекты турында**

Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы "Хуҗәмәт авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы, 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә жирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы №131-ФЗ Федераль законы, Татарстан Республикасының 2018 елның 16 мартындагы "Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үиздарә турында"гы №45-ЗРТ" Законына үзгәрешләр кертү турындагы №10-ЗРТ Законы нигезендә, Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Советы

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы "Хуҗәмәт авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертергә:

1.1 “Ачык тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар ” 19 маддәсенең 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирле әһәмияттәге мәьәләләр буенча муниципаль норматив-хокукый актлар проектларын тикшерү өчен Җирлектә яшәүчеләр, Җирлек Советы, Җирлек Башлыгы, Җирлек Башкарма комитеты катнашында ачык тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар уздырылырга мөмкин”.

1.2 “Ачык тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар” 19 маддәсенең 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Ачык тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар халык яисә Җирлек Советы, Җирлек Башлыгы, җирлек Башкарма комитеты инициативасы буенча уздырыла.

Халык яисә Җирлек Советы инициативасы буенча уздырыла торган ачык тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар Җирлек Советы тарафыннан билгеләнә, Җирлек Башлыгы инициативасы буенча – Җирлек Башлыгы, ә Җирлек Башкарма комитеты инициативасы буенча – Җирлек Башкарма комитеты”.

1.3 «Гражданнар җыены” 22 маддәсенең 3 өлеше, 10 п.пунктнын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

10) яңадан барлыкка килгән җирлек булдыру турында халык инициативасын тәкъдим итү максатларында, шулай ук сайлау хокукына ия булган халык саны 300 дән күбрәк булса, яңадан барлыкка килгән җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасын билгеләү мәсьәләләре буенча авыл арасындагы территориядә урнашкан торак пунктта;

1.4 28 маддәне түбәндәге эчтәлектәге 8 пункт белән тулыландырырга:

«п.8.Җирлек халкы санының артуы яисә кимүе белән бәйле рәвештә Җирлек Советы депутатлары санын арттыручы яисә киметүче үзгәрешләр күрсәтелгән үзгәрешләрне кертү турындагы муниципаль норматив хокукый актны кабул иткән Җирлек Советы вәкаләтләре чыгу белән көченә керә”.

2. Гамәлдәге карарны Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Идарәсенә җибәрергә.

3. Гамәлдәге карар 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы №131-ФЗ Федераль законының 44 маддәсендә каралган тәртиптә көченә керә.

Совет рәисе Г.Г.Вильданова

ТР Минзәлә муниципаль районының
Хуҗәмәт авыл җирлеге Советы карарына
Кушымта №2
16.08.2019 № 1

ТР Минзәлә муниципаль районы Хуҗәмәт авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы "Хуҗәмәт авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында"гы ТР Минзәлә муниципаль районы Хуҗәмәт авыл җирлеге Советы Карары проекты турында"гы Карары проекты буенча ачык тыңлаулар уздыру

ТӘРТИБЕ

1. Яңа редакциядәге муниципаль берәмлек Уставы проекты буенча ачык тыңлаулар (алга таба – ачык тыңлаулар) Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Хуҗәмәт авыл җирлеге Уставының 19 маддәсе нигезендә уздырыла.

2. Ачык тыңлаулар уздыру датасына кадәр 7 көннән соңармыйча язмача гариза тапшырган җирлектә яшәүчеләр үз тәкъдимнәрен нигезләү өчен чыгыш ясау хокукы булган ачык тыңлауларда катнашучылар була.

3. Җирлекнең кызыксынучан халкы ачык тыңлауларда чыгыш ясау хокукы булмаган ачык тыңлауларда катнашучылар була.

4. Катнашучыларны теркәү ачык тыңлаулар башланганчы 30 минут кала башлана.

5. Авыл җирлеге башлыгы ачык тыңлауларда рәислек итүче була.

6. Ачык тыңлаулар катнашучыларга тикшерелә торган мәсьәләнең асылын, ачык тыңлаулар уздыру тәртибен җиткерүче рәислек итүченең кереш сүзеннән башлана.

7. Беркетмәне раслау, кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, рәислек итүченең тәкъдиме буенча рекомендацияләрне рәсмиләштерү өчен җитәкче һәм секретариатның ике әгъзасы составында секретариат сайлана.

8. Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Хуҗәмәт авыл җирлеге Советы депутаты, Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Хуҗәмәт авыл җирлеге Советы карары белән вәкаләтле вәкил төп доклад белән чыгыш ясый.

9. Ачык тыңлауларда чыгыш ясау хокукы булган катнашучылар гариза тапшыру вакытына бәйле рәвештә, чират тәртибендә үз тәкъдимнәрен нигезләү өчен чакырылалар.

10. Ачык тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары 5 минуттан артык була алмый.

11. Ачык тыңлауларда катнашучылар чыгыш тәмамлангач, рәислек итүченең рөхсәте белән чыгыш ясаучыларга сораулар бирергә хокуклы.

12. Ачык тыңлауларда катнашучыларның ачык тыңлаулар барышына тыкшынырга, аларны бүлдерергә һәм уздырырга комачау итәргә хокукы юк.

13. Ачык тыңлаулар уздырганда тәртип саклау ачык тыңлауларда катнашуның мәҗбүри шарты булып тора.

14. Катнашучылар ачык тыңлауларны уздыру тәртибен бозган очракта, рәислек итүче аның утырышлар залыннан чыгып китүен таләп итәргә хокуклы. 15. Чыгышлар тәмамланганнан соң рәислек итүче ачык тыңлаулар барышында яңгыраган тәкъдимнәрне, рекомендацияләрне анықлау өчен секретариат җитәкчесенә сүз бирә ала.

16. Ачык тыңлауларда катнашучыларның барлык күрсәтмәләре һәм тәкъдимнәре язмача формада секретариатка тапшырыла һәм ачык тыңлаулар беркетмәсенә теркәлә. Ачык тыңлаулар беркетмәсе рәислек итүче тарафыннан имзалана һәм билгеләнгән тәртиптә ТР Минзәлә муниципаль районының Хуҗәмәт авыл җирлеге Советы материалларында саклана.

17. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча йомгаклау эшче төркем тарафыннан әзерләнә.

18. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча йомгаклау халыкка җиткерелергә тиеш.

19. Ачык тыңлауларны уздыруны оештыру һәм матди-техник тәэмин ителеш ТР Минзәлә муниципаль районының Хуҗәмәт авыл җирлеге Советы аппараты тарафыннан гамәлгә ашырыла.